КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 июнь г.Казань № 724

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Барыш - Кама Тамагы - Келәнче төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VI$^{I}$ бүлегендәге 49 статьясы, VII1 бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Барыш - Кама Тамагы - Келәнче төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Келәнче авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, Г.К.Гыйзәтуллин (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 4 645 кв.метр мәйданлы, 16:22:010303:102 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 134 000 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Басып алына торган җир кишәрлегендә урнашкан 16:22:000000:1099 кадастр номерлы «Юл транспорты корылмалары. Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Барыш - Кама Тамагы - Келәнче» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» капиталь төзелеш объектын тартып алырга ярамый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Главтатдортрanska Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районында «Казан - Ульяновск» - Иске Барыш - Кама Тамагы - Келәнче» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объектын планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын раслау турында» 2019 ел, 26 июнь, 506 нчы карары белән расланган планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты нигезендә 16:22:000000:102 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин